ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2023 елның «18» гыйнварыннан № 10

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) хәрәкәте мәсьәләләре буенча совет төзү турында

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә эшчәнлек алып баручы ирекле ярдәмчелек берләшмәләре (волонтерлык) эшчәнлеген үстерү һәм аларга ярдәм итү максатларында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) хәрәкәте мәсьәләләре буенча совет төзергә.

2. Кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) хәрәкәте мәсьәләләре буенча советытурында нигезләмәне расларга.

3. Кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) хәрәкәте мәсьәләләре буенча советы составын расларга.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районы рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Л.К. Исхакова

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның «18» гыйнварыннан 10 номерлы карары белән расланган

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) хәрәкәте мәсьәләләре буенча совет турында нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) мәсьәләләре буенча совет (алга таба - Совет) Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты каршында даими эшләүче консультатив орган булып тора, ул җирле үзидарә органнарының, иҗтимагый берләшмәләрнең, социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмаларның, ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) оешмаларының, ирекле ярдәмчелекне (волонтерлыкны) үстерүдә көчләрне берләштерү максатларында даими эшләүче консультатив орган булып тора.

1.2. Совет үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы карарлары һәм күрсәтмәләре, Татарстан Республикасының башка хокукый актлары, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының норматив хокукый актлары һәм әлеге Нигезләмә белән җитәкчелек итә.

2. Советның максатлары һәм бурычлары

2.1. Советның максаты: Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының иҗтимагый берләшмәләре эшчәнлеген координацияләү, ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) үсешендә көчләрне берләштерү.

2.2. Советның бурычлары:

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының җирле үзидарә органнарының иҗтимагый берләшмәләр, социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар, ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) оешмалары һәм башка кызыксынган оешмалар белән үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү;

социаль бурычларны хәл итүдә ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) оешмаларының һәм ирекле ярдәмчеләрнең ихтыяҗын тәэмин итә торган шартлар тудыру;

ирекле ярдәмчелекне киңәйтү һәм ныгыту өчен шартлар тудыру, гамәлдәге оешмалар эшчәнлегенә ярдәм итү һәм яңа ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) оешмалары барлыкка килү өчен шартлар тудыру, аларның потенциалын күтәрүгә ярдәм итү;

ирекле ярдәмчелек эшчәнлегенә методик, мәгълүмати, консультация ярдәме күрсәтүнең инфраструктурасын үстерү;

ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) эшчәнлеге чараларын үткәрүгә халыкны җәлеп итү механизмнарын эшләү;

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) өлкәсендә эшчәнлекне җайга сала торган хокукый актлары проектлары турында фикер алышу. Ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) эшчәнлеген үстерүгә юнәлдерелгән гамәлдәге чараларның нәтиҗәлелеге предметына кабул ителгән хокукый актларны һәм хокук куллану практикасын анализлау.

## 3. Советның төп функцияләре

Совет түбәндәге функцияләрне үти:

вәкиллек;

координацияләү;

мәгълүмати.

## 4. Советның хокуклары

4.1. Совет түбәндәгеләргә хокуклы:

4.1.1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының региональ башкарма хакимият органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан Совет компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләр буенча кирәкле документлар һәм белешмәләр соратып алырга.

4.1.2. Ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) үсешендә көчләрне берләштерү максатларында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр, социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар, ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) оешмалары һәм башка кызыксынган оешма вәкилләрен Совет утырышына чакырырга.

4.2. Дәүләт, муниципаль хакимият органнарына ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) үсеше мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр бирергә.

## 5. Советның эш тәртибе

5.1. Совет составына Совет рәисе, Совет рәисе урынбасары, секретаре, ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) эшчәнлегенең төп оештыручылары, шул исәптән социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар, ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) төркемнәре лидерлары, иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмалар, Совет составына керүгә үзенең ризалыгын язма рәвештә белдергән предприятиеләр керә.

5.2. Вазыйфасы буенча Совет рәисе - мәгариф, социаль өлкә һәм яшьләр сәясәте мәсьәләләрен алып баручы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (социаль мәсьәләләр буенча).

5.3. Совет составы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

5.4. Совет эше белән - Совет рәисе, ә ул булмаганда аның урынбасары җитәкчелек итә.

5.5. Совет утырышларны кирәк булганда уздыра.

5.6. Совет рәисе үз вәкаләтләре кысаларында:

Совет утырышын уздыру турында карар кабул итә, көн тәртибен билгели;

Совет кабул иткән карарларның үтәлешен тәэмин итә һәм тикшереп тора;

үз компетенциясе чикләрендә Совет әгъзаларына йөкләмәләр бирә.

5.7. Совет утырышында аның әгъзаларының гомуми санының яртысыннан артыгы катнашса, ул тулы хокуклы дип санала.

5.8. Көн тәртибендәге мәсьәләләр буенча материаллар Совет утырышына үз компетенцияләре кысаларында Совет әгъзалары тарафыннан әзерләнә. Материаллар Совет утырышы көненә кадәр өч көннән дә соңга калмыйча Совет секретарена тапшырыла.

5.9. Совет карарлары Совет утырышында катнашучы Совет әгъзалары тарафыннан күпчелек тавыш белән кабул ителә һәм Совет утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә. Тавышлар тигез булган очракта, утырышта рәислек итүче тавышы хәлиткеч булып тора. Совет карарлары тәкъдим итү характерына ия.

5.10. Совет утырышы беркетмәсе Совет утырышыннан соң 5 эш көне эчендә рәислек итүче һәм Совет секретаре тарафыннан имзалана.

5.11. Совет утырышы беркетмәсендә күрсәтелә:

Совет утырышын уздыру датасы, вакыты һәм урыны;

Совет утырышының расланган көн тәртибе;

Совет әгъзаларының һәм чакырылган башка затларның исемнәре һәм вазыйфалары;

Совет утырышының көн тәртибенә кагылышлы кабул ителгән карарлар.

5.12. Совет утырышлары беркетмәләре яисә алардан кирәкле өземтәләр Совет секретаре тарафыннан йөкләмәләрне үтәү өчен җаваплы вазыйфаи затларга Совет утырышы көненнән алып 5 эш көне эчендә җибәрелә.

5.13. Совет эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итүне Совет секретаре гамәлгә ашыра.

Татарстан Республикасы Яңа
Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2023 елның «18» гыйнварыннан
10 номерлы карары белән
расланган

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) хәрәкәте мәсьәләләре буенча советы составы

Совет рәисе:

| | |
|---|---|
| Еронтьев Александр Леонидович | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасары (социаль мәсьәләләр буенча) |

Совет рәисе урынбасары:

| | |
|---|---|
| Магомедова Марина Александровна | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы |

Совет секретаре:

| | |
|---|---|
| Маланчева Снежана Александровна | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы «Аҗаган» яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клубы» муниципаль бюджет учреждениесенең өстәмә белем педагогы |

Совет әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Бутина Анна Ивановна | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты мәгариф бүлеге башлыгы |
| Васильева Светлана Анатольевна | «ЕДИНАЯ РОССИЯ» партиясенең Яңа Чишмә җирле бүлекчәсе башкарма секретаре (килешү буенча); |
| Гурьева Наталья Николаевна | Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Яңа Чишмә муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Завалишина Наталья Александровна | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Кашапова Нәзирә Нәдирҗан кызы | Татарстан Республикасы Социаль яклау министрлыгының Яңа Чишмә муниципаль районында «Забота» халыкка социаль хезмәт күрсәтү үзәге директоры вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча) |
| Лизунова Залина Наилевна | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Өлкәннәр һәм инвалидлар өчен Яңа Чишмә интернат йорты» ДАУСО директоры (килешү буенча) |
| Мусин Азат Вәлиҗан улы | «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «ЯңаЧишмә хәбәрләре» газетасы редакциясе» директоры - баш мөхәррире (килешү буенча) |
| Носова Галина Александровна | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге башлыгы |
| Роменская Наталья Александровна | «Яңа Чишмә РҮХ» ДАССУнең баш табибы вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча) |
| Селиверстова Дарья Михайловна | «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «ФОРПОСТ» җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр һәм мәктәп формированиеләре үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе директоры |
| Хөснуллина Резеда Гайсә кызы | «Яңа Чишмә районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Янова Евгения Петровна | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы «Балалар иҗат үзәге» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениясе директоры; |